Каралган.
Башлангыч сыйныфлар
Метод берлэшмэсе
Утырышында.
Протокол №1, 31 август 2023 ел.
Житэкчесе ------Музаффарова Р.М.

Килешенгэн.
Укыту эшлэре буенча
директор урынбасары
______Махмутова А.Р.

**2023-2024 нче уку елына Кайбыч топ гомуми белем мәктәбенең башлангыч сыйныф укытучыларының методик берләшмә планы**

**Методик тема:**

Белем алу һәм үзүсешне дәвам итәргә этәргеч бирүче танып-белү мотивациясе формалаштыру.

**Максат:**

Укучы шәхесенең иҗади үсешен тәэмин итү.

**Бурычлар:**

1.Укытучының белем бирү һәм методик осталык дәрәҗәсен күтәрү.

2. Сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү максатыннан заманча дәрес үткәрү юлларын тагын да нигезле өйрәнү, инновацион технологияләрдән актив файдалану.

3. Ныклы исәпләү күнекмәләре формалаштыру һәм логик фикерләүне үстерү максатыннан эшнең төрле форма һәм методларын куллануны камилләштерү; орфографик сизгерлекне, уку техникасын үстерү өстендә эшне камилләштерүгә булышлык итү.

4.Укыту-тәрбия процессында укучыларның физик сәламәтлекләрен ныгыту өстендә эшләү.

5. Халык традицияләренә нигезләнгән бәйрәм һәм дәресләр аша укучыларга әхлак тәрбиясе бирү.

6. Сәләтле балалар белән эшне максатчан оештыру.

7.Үзләштерү дәрәҗәсе төрле булган укучыларга педагогик ярдәм күрсәтү.

8 . Укыту-тәрбия эшендә милли- региональ материаллардан файдалану.

**I нче утырыш (август)**

**Тема: 2023-2024 нче уку елына эш планын раслау. Яңа уку елына бурычлар.**

Көн тәртибе:
1.Узган уку елындагы методик эшкә йомгак ясау.
2. Башлангыч сыйныф укытучылары методик берләшмәсе алдында торган бурычлар.
3. Дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләрне барлау.
4. Электрон журнал тутыруга, балаларның көндәлекләрен, дәфтәрләрен алып баруга бердәм таләпләр.Бащлангыч сыйныфларда бердәм орфографик режимга тозэтмэлэр керту.
5. Эш программаларын карау.

**Утырышлар арасындагы эш:**
1.Кабинетларда эш, дидактик материаллар эшләү.
2. Тәрбия планнарын төзү.
3. Ата-аналар җыелышын үткәрү.
4. Контроль эшләр үткәрү.
5. Үзара дәресләргә керү.
6. Эш программаларына төзәтмәләр кертү.

**Традицион чаралар:**
“ Белем бәйрәме”,”Укытучылар көне”,”Уңыш бәйрәме”,  “Өлкәннәр көне”н билгеләп үтү, көзге табигатькә экскурсия.

**II нче утырыш (октябрь)**

**Тема: Предметара бәйләнешләр нигезендә кече яшьтәге балаларда экологик культура формалаштыру.**

Көн тәртибе:

1.1 сыйныфта ачык дэрес.(Музаффарова Р.М.)
2.«Укучыларда экологик  культура формалаштыру» дигэн темага фикер алышу.
3. Башлангыч сыйныфлар атналыгын планлаштыру.
4. 1 нче сыйныф укучыларның адаптация чоры. (Музаффарова Р.М.)

**Утырышлар арасындагы эш:**
1. I яртыеллык өчен контроль эшләр һәм тестлар.
2. I яртыеллык өчен уку күнекмәләрен тикшерү.
3. Укытучыларның ачык дәресләре.
4. Ата- аналар җыелышы уздыру.

**Традицион чаралар**:
1.“Әниләр көне” бәйрәме, “Яңа ел “ бәйрәме, “Юл йөрү кагыйдәләрен беләсезме?” темасына класстан тыш чара.

**Ш нче утырыш (декабрь)**

**Тема: Математика дәресләрендә укучыларның исәпләү күнекмәләрен камилләштерү.**

Көн тәртибе:

1.”Сәләтле балалар белән эшләү” темасы буенча доклад. (Музаффарова Р.М..)
2. “Түгәрәк өстәл”:”Математика дәресләрендә укучыларның исәпләү күнекмәләрен камилләштерү”:
а) укытучының эйлэнэ- тирэ донья дәресенә әзерләнүе (һәр укытучы),
б) телдән исәпләүне оештыру алымнары,
в) математика дәресендә укучыларның мөстәкыйль эшен оештыру.3-4 сыйныфларда ачык дэрес.Математика.Шарафутдинова Г.И.
3. Педагогик әдәбият яңалыклары.
4. Олимпиадаларга әзерлек .

**Утырышлар арасындагы эш:**
1 Укытучыларның үзбелемнәрен күтәрүләре.
2. Контроль эшләр үткәрү һәм анализ.
3. Үзара дәресләргә керү.
4. Башлангыч сыйныфлар атналыгы үткәрү.
5. Интерактив такта белән эшләү күнекмәләре булдыру өстендә эш.

**Традицион чаралар:**
“Ягез әле, егетләр!” бәйрәме, ”Күңелле стартлар”, “Китап сөючеләр”.

**IV нче утырыш (март)**

**Тема: Укыту процессында укучыларның логик фикерләү сәләтләрен үстерү.**

Көн тәртибе:

1.“Грамоталы язуны камилләштерү” доклад(Мозаффарова Р.М.)

2. I- IV класс укучыларының  орфографик хаталарын кисәтү алымнары.
3. 4 сыйныфта ачык дэрес.Татар теле.Шарафутдинова Г.И.
4. Рус теле дәресләрендә сүзлек эше.
5. Дәресләрдә логик фикерләүне үстерү турында.

**Утырышлар арасында эш:**
1. Интерактив такта белән эшләү күнекмәләре булдыру өстендә эш.
2. Ата-аналар җыелышы.
3. Фәннәр буенча олимпиада.

**Традицион чаралар:**
Гаилә бәйрәмнәре, “Кошлар - безнең дуслар”, “Сәламәтлек көне”.

**V нче утырыш (май)**

**Тема: Методик берләшмә эшенә анализ**

Көн тәртибе:

1. Контроль эш нәтиҗәләре.
2. Укытучылар һәм укучылар катнашкан конкурслар. Олимпиада нәтиҗәләре.
3. 2023-2024 нче уку елына МБ эшчәнлегенә анализ. Алдагы уку елына бурычлар.

**Утырышлар арасында эш:**
1. Еллык контроль эшләр
2. Укучыларның уку күнекмәләрен тикшерү
3. Ата-аналар җыелышы үткәрү.(дистанцион)

**Традицион чаралар:**
“Җиңү бәйрәме”, “Соңгы кыңгырау” бәйрәмнәре, табигатькә экскурсия.

**Балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәп арасында дәвамчылык булдыруда методик берләшмәнең эш планы**

2023 -2024 нче уку елы

| № | Эш төре | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Кайбыч "Кояшкай" балалар бакчасы мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының "Белем бәйрәме"ндә катнашулары. | 1.09 | Сунгатуллина В. |
| 2 | Мәктәп, спорт мәйданчыгы, тәҗрибә участокларына экскурсия. | октябрь | Сунгатуллина В. |
| 3 | "Мәктәптә белем бирү бервакытта да буш урыннан башланмый, ә һәрвакыт бала үсешенең аерым бер стадиясенә таяна". Әзерлек төркеме занятиеләрендә булу, әңгәмә. | даими | Сунгатуллина В. Музаффарова Р.М. |
| 4 | Зурлар төркеме балалары белән мәктәпнең башлангыч сыйныфларына экскурсия. 1 нче сыйныфта технология дәресендә булу. | декабрь | Шарафутдинова Г.И. Музаффарова Р.М. Сунгатуллина В. |
| 5 | Әзерлек төркеменә йөрүче балаларны "Әлифба" бәйрәменә чакыру. | февраль | Музаффарова Р.М. |
| 6 | Балалар бакчасында ата-аналар җыелышында катнашу. "Булачак 1нче сыйныф укучысының көндәлек режимын оештыру. Баланы мәктәпкә укырга әзерләү" темасына чыгыш. | график нигезендә | Музаффарова Р.М. |
| 7 | Кайбыч "Кояшкай" балалар бакчасы мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының "Соңгы кыңгырау" бәйрәмендә катнашулары. | 25.05 | Сунгатуллина В.. |
| 8 | Балалар бакчасында "Сау бул, бакча" бәйрәмендә катнашу. | 31.05 | Сунгатуллина В.Музаффарова Р.М., Шарафутдинова Г.И. |